**Балалар бакчалары җитәкчеләре утырышы беркетмәсе №1.**

**Үткәрү вакыты**: 03.09.2020.
**Үткәрү урыны:** Балалар иҗат үзәге.
**Катнашнашырга тиеш**: район мәгариф бүлеге мәктәпкәчә белем бирү буенча методист Ахтямова А.А., РМО җитәкчесе Аглямова М.В., балалар бакчалары мөдирләре, өлкән тәрбиячеләр.
**Катнашалар**: 42 бакча мөдире, 5 өлкән тәрбияче, РМО җитәкчесе Аглямова М.В., район мәгариф бүлеге мәктәпкәчә белем бирү буенча методист Ахтямова А.А.

**Тема:** "Үткән уку елына анализ. Яңа уку елына эшчәнлек планнарын билгеләү»

**Көн тәртибе**:
1. Пандемия чорына куелган таләпләр. Л.М. Хафизова чыгышы.
2. "Яшел ут 2020" конкурсына нәтиҗә ясау. Лена Музаятовна чыгышы.
3. Узган уку елына йомгак ясау. Район мәгариф бүлеге мәктәпкәчә белем бирү буенча методист Ахтямова А.А. чыгышы.
4. "Электрон балалар бакчасы" Лейла Фазыловна чыгышы.
5. "Балалар бакчасында цифрлы технологияләр куллану ". Гомуми үсеш бирүче 1 санлы балалар бакчасы мөдире Закирҗанова Л.Р. чыгышы.
6. Башлангыч мәктәп-балалар бакчасында инглиз телен өйрәнүне тормышка ашыруда цифрлы караш. Р.Файзрахманова чыгышы.
7. Уен тренинг

**Утырыш барышы:**

1 нче көн тәртибе буенча сүз Л.М. Хафизовага бирелде, ул районда коронавирус буенча ситуация торышы белән таныштырды.

1. Бу уку елында эшне пандемия чорында башлап җибәрдек, барыбызда югарыдан төшерелгән САНИТАРНО-ЭПИДЕМИОЛОГИЧЕСКИЕ ПРАВИЛА СП 3.1/2.4.3598-20 "САНИТАРНО-ЭПИДЕМИОЛОГИЧЕСКИЕ ТРЕБОВАНИЯ К УСТРОЙСТВУ, СОДЕРЖАНИЮ И ОРГАНИЗАЦИИ РАБОТЫ ОБРАЗОВАТЕЛЬНЫХ ОРГАНИЗАЦИЙ И ДРУГИХ ОБЪЕКТОВ СОЦИАЛЬНОЙ ИНФРАСТРУКТУРЫ ДЛЯ ДЕТЕЙ И МОЛОДЕЖИ В УСЛОВИЯХ РАСПРОСТРАНЕНИЯ НОВОЙ КОРОНАВИРУСНОЙ ИНФЕКЦИИ (COVID-19)" таләпләренә катгый таянып эш оештыру шарт. Бу документ хезмәткәрләр белән өйрәнелергә һәм үтәлергә тиеш.
2. Районга Гриппка каршы профилактика вакциналары кайтты. Һәр мәгариф системасында хезмәт күрсәтүче дә бу прививкаларны ясатырга тиеш. Озакламый балалар өчен дә кайтып җитә, ата-аналар белән аңлату эшләре алып бирү кирәк, курыкмасыннар, дөрес аңласыннар иде, вакциналарның зыяны юклыгын.
3. Бала килми торган очракта справкалы булу катгый тикшереләчәк.
4. Бала балалар бакчасына алынган чагында Манту прививкасы булу шарт яисә педиатр, фтизиатр тарафыннан бирелгән справкасы булсын.
5. флюорографиясез бер хезмәткәр дә булмый.
6. иртән һәр хезмәткәр, һәр бала фильтр үтеп кенә учреждениягә керә. Авыру билгеләре булган очракта, табибка җибәрелергә тиеш була.

Инструкцияләрне бозып авыру очрагы теркәлсә, закон тарафыннан җаваплылыкка тартылу карaралган, шуңа күрә бер беребезнең сәламәтлеген саклап эш итик.

2 көн тәртибе буенча сүзне ЮХИДИ буенча белгеч Лена Музаятовна алды.
Сүз башында республикада һәм районда юл йөрү куркынычсызлыгы турында мәгълүмәт белән таныштырды. Соңрак февраль аенда узган "Яшел ут - 2020" конкурсына нәтиҗә ясады, район буенча җиңүче балалар бакчаларын, аеры номинациядә җиңүче тәрбиячеләрне котлады, истәлекле бүләкләр тапшырды.
"Игътибар , балалар" акциясе булып үтүен билгеләде, актив катнашкан балалар бакчаларына рәхмәтен белдерде.

3 көн тәртибе буенча район мәгариф бүлеге мәктәпкәчә белем бирү буенча методист Ахтямова А.А. узган уку елына анализ ясады, проблемалы өлешләрне аеруча билгеләде, мәсалән:

1. педагогларны категория алу, үз үзеңне үстерү өстендә эшләү кирәклеген ассызыклады,
2. белемнәре буенча көчле балаларны олимпиадага актив катнаштыру кирәклеген билгеләде.
3. балаларны бакчадан бакчага күчерүне үтенеп керүче ата-аналар ешайды, ата-аналар белән эшне, аралашу стилен карап бетерү соралды.
4. Грантларга актив катнашу кирәклеген әйтте.

Пандемия чорында тиз арада эшне оештырып башкарган дежур 2 санлы балалар бакчасына, хезмәткәрләргә рәхмәт белдерелде. Хәзер инде эшли башлаган барлык бакчаларга да таләпләрне үтәп эшне алып барырга дип йөкләнде.

Җитәкче тарафыннан алдагы уку елына бурычлар, планнар билгеләнде.

4 көн тәртибе буенча сүзне Сафина Лейла Фазыловна алды . Ул “Электрон балалар бакчасы” программасында эш торышы белән таныштырды. Соңгы эш итеп плановый группалардан фактически га күчү булды, эшне кимчелекләрсез башкарып чыктык, диде. Бакчага балалар чираты юк дияргә дә була, булганы да ясле яшендәге балалар, 2 балалар бакчасында ул группалар булдыру планда тора.

5 көн тәртибе. “Балалар бакчасында цифрлы технологияләр куллану ”. Гомуми үсеш бирүче 1 санлы балалар бакчасы мөдире Закирҗанова Л.Р. презентацияле чыгыш ясады, тәҗрибәсе белән уртаклашты.

6 көн тәртибе. Башлангыч мәктәп-балалар бакчасында инглиз телен өйрәнүне тормышка ашыруда цифрлы караш. Мәктәп-бакча мөдире Р.Файзрахманова презентацияле чыгыш ясады, кызыклы фикерләрен әйтте, мөдирләрнең кызыксындырган сорауларына җавап бирде.

7 Яңа Әлем балалар бакчасы методисты Хафизова А. уен тренинг уздырды, бакча мөдирләре теләп катнашты, ял итеп күңел ачты.

8. Төрлеләр:
- 24 август - 6 сентябрь ПДД буенча мероприятияләр уздырып фотоотчетларын РООга җибәрергә,
- 10 -20 сентябрь экологический конкурс “Светлячок”,
- “Юный эрудит” 12 сентябрьдә, регистрация 4 сентябрьгә кадәр,
- “Воспитатель России” конкуры була,танышырга.

**Карар:**

1. Балалар бакчасында цифрлы технологияләр куллануны максат итеп куярга, 1 санлы балалар бакчасы һәм мәктәп бакча эшен үрнәк итеп алырга;
2. Пандемия чоры таләпләрен катгый үтәп эшчәнлекне алып барырга.

Район мәгариф бүлеге мәктәпкәчә белем бирү буенча методист : ___________ Ахтямова А.А.
Сәркатип: ____________ Шакурова Р. Д.